Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

11 ноябрь, 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Керәшен Сәрдәсе авылында. Халык җыенын өч этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан урамы, 6а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Татарстан урамы, Совет урамының 28-65 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан урамы, 6а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының 66-106 йортлары, Болын урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2019 елның 7 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Совет урамы, 6а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Гагарин, Яшьләр урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Керәшен Сәрдәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Көлкәмәр авылында. Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 27 ноябрендә,10 сәгать 00 минутта, Мәктәп урамы буенча Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар һәйкәле янында үтәчәк. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп урамының 4-14, 42-45 йортлары, Амбар урамының 30-61 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 30 ноябрендә,10 сәгать 00 минутта, Югары урамдагы 59 йорт янында үтәчәк. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп урамының 48-52, 16-20 йортлары, Амбар урамының 26 йорты, Югары урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Керәшен Сәрдәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов